| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 21 ноябре** **Чистай шәһәре** **№36/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 11 февралендәге 45/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 11 февралендәге 45/2 номерлы карары (Чистай шәһәр Советының 13.05.2020 ел, №46/2, 28.10.2020 ел, №3/2, 22.10.2021 ел, №10/2, 12.05.2022 ел, №14/2, 02.09.2022 ел, №16/1, 16.02.2023 ел, №20/2, 30.05.2024 ел №30/2 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 9 пунктында:

1.1.1. 7 пунктчада «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча,"» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле яңа 8 пунктча өстәргә:

«9) бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгели;».

1.2. 38 статьяда:

1.2.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа 2 абзац өстәргә:
«-бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

1.2.2. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа 3 абзац өстәргә:
«-агымдагы финанс елында гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондына федераль бюджеттан бирелә торган бюджетара трансфертларның гомуми күләме чикләрендә гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджеты турында закон нигезендә, башкарма хакимиятнең Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыручы федераль органы тәкъдиме нигезендә, Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларының җыелма бюджет язмаларына тиешле үзгәрешләр кертеп,;»;

1.2.3. 3 пунктның 11 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2.4. 3 пунктның соңгы абзацында «норматив йөкләмәләрне» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 7 пунктының егерме бишенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И. Ксенофонтов